**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 30 октябрь № 828

г. Казань

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре арасында «Сәламәтлек территориясе» исеменә республика конкурсы турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2015 елда Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре арасында «Сәламәтлек территориясе» исеменә республика конкурсын үткәрергә.

2. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре арасында «Сәламәтлек территориясе» исеменә республика конкурсын үткәрү буенча оештыру комитетын төзергә.

3. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре арасында «Сәламәтлек территориясе» исеменә республика конкурсын үткәрү һәм финанслау тәртибен;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре арасында «Сәламәтлек территориясе» исеменә республика конкурсын үткәрү буенча оештыру комитеты составын.

4. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыкларына Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре арасында «Сәламәтлек территориясе» исеменә республика конкурсында катнашырга тәкъдим итәргә.

5. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре арасында «Сәламәтлек территориясе» исеменә республика конкурсының җиңүчеләре булган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә башка бюджетара трансфертлар бирүгә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының резерв фонды акчасы исәбеннән Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына 3,3 млн.сум бүлеп бирергә.

6. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына конкурсны әзерләүне һәм үткәрүне массакүләм мәгълүмат чараларында мәгълүмати яктыртуны оештырырга.

7. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\828.docx

Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 2015 ел, 30 октябрь, 828 нче карары белән расланды

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре арасында «Сәламәтлек территориясе» исеменә республика конкурсын үткәрү һәм финанслау тәртибе

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре арасында «Сәламәтлек территориясе» исеменә республика конкурсын (алга таба – конкурс) оештыру, үткәрү һәм финанслауга таләпләрне билгели.

2. Конкурсның максатлары һәм бурычлары

2.1. Конкурс Татарстан Республикасы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау максаты белән үткәрелә.

2.2. Конкурсның төп бурычы – халыкның сәламәт яшәү рәвешенә, наркотиклар, алкоголь кулланудан, тәмәке тартудан баш тартуга ихтыяҗын булдыру өчен шартлар тудыру, шул исәптән:

Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарының халык арасында асоциаль тәртипне профилактикалау өлкәсендәге уңай эшчәнлек тәҗрибәсен билгеләү һәм бүләкләү;

иҗтимагый аңга мәгълүмати йогынты ясау, сәламәт яшәү рәвешен алып баруга мотивация стимуллаштыру һәм формалаштыру;

Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар арасында аек яшәү рәвешенең тарихи һәм мәдәни гореф-гадәтләрен торгызу.

3. Конкурста катнашучылар

3.1. Конкурс Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре арасында үткәрелә.

3.2. Әлеге Тәртипкә теркәлгән кушымтада күрсәтелгән форма буенча заявка җибәргән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге Конкурста катнашучы булып санала.

4. Конкурсны оештыру һәм үткәрү

4.1. Конкурсны оештыру һәм аның йомгакларын ясау өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан конкурсны үткәрү буенча оештыру комитеты (алга таба – конкурсны оештыру комитеты) төзелә һәм аның составы раслана.

4.2. Конкурсны оештыру комитеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

конкурс заявкаларын һәм материалларын карау;

йомгаклар ясау һәм конкурста җиңүчеләрне билгеләү.

4.3. Конкурс заявкаларын һәм материалларын карау барышында конкурсны оештыру комитеты кирәк булган очракта, бирелгән мәгълүматларны тәгаенләштерү максатларында, конкурста катнашучылардан өстәмә мәгълүматлар соратып ала.

4.4. Конкурс ике этапта үткәрелә:

I этап – сайлап алу этабы (2015 елның 10 ноябреннән 20 ноябренә кадәр): Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре арасыннан дәгъвачыларны сайлап алуны гамәлгә ашыра – заявка биргән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре арасыннан конкурста катнашучыларның 1/3 өлешеннән артык түгел;

II этап – конкурсны оештыру комитеты әгъзалары тарафыннан җиңүчеләрне билгеләү (2015 елның 24 ноябреннән 4 декабренә кадәр).

4.5. Конкурс һәм аны үткәрү шартлары турында белешмәләр Татарстан Республикасы Хөкүмәте, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советының рәсми сайтларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштырыла.

4.6. Конкурста катнашучылар түбәндәге документларны җыя:

әлеге Тәртипкә теркәлгән кушымта нигезендә конкурста катнашуга заявка;

конкурс материаллары (эшне тасвирлау өлеше) конкурсны үткәрү шартлары нигезендә электрон мәгълүмат саклау җайланмасында (флеш-картада) рус яки татар телләрендә машинкада басылган текстның 25 битеннән артык булмаган күләмдә (А4 форматы; юлара интервал – 1,0; Times New Roman шрифты; шрифт зурлыгы – 14; читләре – 2,5 см) тапшырыла; тематик фотографияләр, графиклар, таблицалар рөхсәт ителә.

4.7. Конкурста катнашуга заявкалар һәм конкурс материаллары 2015 елның 10 ноябренә кадәр Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советына түбәндәге адрес буенча җибәрелә: Казан шәһәре, Кремль, тел./факс: 8-843-293-60-15 (электрон адрес: smort@kabmin.tatarstan.ru).

4.8. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы 2015 елның 23 ноябреннән дә соңга калмыйча конкурсның I этабы нәтиҗәләрен конкурсны оештыру комитетына җибәрә.

## 5. Конкурс нигезендә сайлап алу критерийлары

5.1. Конкурсның I этабында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре өчен сайлап алу критерийлары булып түбәндәгеләр тора:

сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру буенча муниципаль программалар эшләү һәм гамәлгә ашыру – 10 баллга кадәр;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге территориясендә «Гражданнарның сәламәтлеген әйләнә-тирәдәге тәмәке төтене тәэсиреннән һәм тәмәке тарту зыяннарыннан саклау турында» 2013 ел, 23 февраль, ФЗ-15 нче Федераль законны үтәү буенча чараларны гамәлгә ашыру – 10 баллга кадәр;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге территориясендә «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм әйләнештә йөртүне дәүләт тарафыннан җайга салу һәм алкогольле продукция куллануны (эчүне) чикләү

турында» 1995 ел, 22 ноябрь, ФЗ-171 нче Федераль законны үтәү буенча чараларны гамәлгә ашыру – 10 баллга кадәр;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге территориясендә халыкның сәламәт ялы өчен шартлар тудыру – 10 баллга кадәр;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге территориясендә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру – 10 баллга кадәр;

«Хезмәткә һәм саклауга әзер» (ХСӘ) бөтенроссия физкультура-спорт комплексы нормативларын бирү буенча халык арасында ярышлар оештыру һәм үткәрү – 10 баллга кадәр;

массакүләм профилактика акцияләрен оештыру, шул исәптән Татарстан Республикасы территориясендә «Гражданнарның сәламәтлеген әйләнә-тирәдәге тәмәке төтене тәэсиреннән һәм тәмәке тарту зыяннарыннан саклау турында» 2013 ел, 23 февраль, ФЗ-15 нче Федераль законны үтәү мәсьәләләре буенча 2015 елда республика айлыгын (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 18 май, б-1023 нче боерыгы нигезендә) һәм «Аеклык бәйрәме» республика акциясен (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 5 август, б-1710 нчы боерыгы нигезендә) үткәрүдә катнашу – 20 баллга кадәр;

муниципаль берәмлекләрнең сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү, заманча мәгълүмат технологияләрен куллану, шул исәптән тематик интернет-сайтлар (сәхифәләр) булдыру һәм аларны актуальләштерү – 10 баллга кадәр;

халыкка мәгълүмат җиткерү буенча тышкы чаралар куллану, басма продукция әзерләү һәм тарату (мәгълүмати плакатлар, баннерлар, сузылма язулар) – 10 баллга кадәр.

5.2. Конкурсның II этабына заявка биргән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре арасыннан конкурста катнашучыларның 1/3 өлешеннән артык булмаган күләмдә иң күп балл җыйган катнашучылар үтә.

6. Конкурс эшләрен бәяләү һәм конкурска йомгаклар ясау

6.1. Конкурс материалларын бәяләү өчен конкурсны оештыру комитеты составына кергән Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары вәкилләре арасыннан эшче төркем төзелә (10 кешедән ким түгел). Эшче төркем составы конкурсны оештыру комитеты рәисе тарафыннан раслана.

6.2. Эшче төркемнең төп вазыйфалары түбәндәгеләр:

конкурс материалларын карауны тәэмин итү;

конкурска тәкъдим ителгән материаллар эчендә булган мәгълүматларның дөреслеккә туры килүен тикшерү, шул исәптән (конкурс кысаларында алынган мәгълүматны тәгаенләштерү кирәк булган очракта) урынга барып;

конкурска йомгаклар ясауны тәэмин итү.

6.3. Конкурска йомгаклар ясау буенча эшче төркем тәкъдимнәре конкурсны оештыру комитеты утырышына кертелә һәм анда катнашкан әгъзалар (составның 2/3 өлешеннән ким түгел) тавышларының күпчелеге белән җиңүчеләр турында карар кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, рәислек итүче (оештыру комитеты рәисе яки аның урынбасары) тавышы хәлиткеч санала.

Карар беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм конкурсны оештыру комитеты рәисе тарафыннан имзалана.

6.4. Конкурс йомгаклары Татарстан Республикасының массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртыла.

7. Конкурста җиңүчеләрне бүләкләү

7.1. Конкурста җиңүчеләрне бүләкләү тантаналы рәвештә үткәрелә.

7.2. Конкурста җиңүчеләргә грантлар бирелә:

I урын өчен – 1 500 000 сум;

II урын өчен – 1 000 000 сум;

III урын өчен – 800 000 сум.

8. Конкурсны финанслау

8.1. Татарстан Республикасы бюджеты акчасы Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан конкурста җиңүчеләр дип танылган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына грантлар бирү максатларында күздә тотылган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә башка бюджетара трансфертлар рәвешендә күчерелә.

Башка бюджетара трансфертлар акчасын бүлү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

8.2. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре:

башка бюджетара трансфертлар рәвешендә алынган акчаны, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, алкоголь белән артык мавыгуны, наркотиклар һәм психотроп матдәләр куллануны профилактикалау эшен оештыру өчен, түбәндәге чыгымнар төрләре буенча юнәлтә: чаралар оештыру һәм үткәрү, канцелярия товарлары, типография продукциясе, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү чараларын үткәрү; җиһазлар һәм инвентарь сатып алу;

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына хисап елыннан соң килә торган елның 20 гыйнварына кадәр күрсәтелгән акчадан файдалану турында финанс хисабы кертә (хисап формасы Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан 2015 елның 20 декабренә кадәр әзерләнә һәм билгеләнә).

8.3. Грантлар түләүгә бирелгән акча, аннан максатчан файдаланмау һәм (яки) дөреслеккә туры килмәгән хисаплылык тапшыру ачыклануга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы таләбен алган көннән 60 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты керемenә кайтарылырга тиеш.

8.4. Грантлар түләүгә бирелгән акчадан максатчан файдалануга контроль үткәрү максатларында, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр билгеләнгән тәртиптә күрсәтелгән акчаны файдалану турында финанс хисабын Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына кертергә тиеш.

______________________________

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре арасында «Сәламәтлек территориясе» исеменә республика конкурсын үткәрү һәм финанслау тәртибенә кушымта

Форма

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре арасында «Сәламәтлек территориясе» исеменә республика конкурсында катнашуга заявка

| Т/с | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге – конкурста катнашучы турында белешмә | Мәгълүматлар |
|---|---|---|
| 1. | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең тулы исеме (устав нигезендә) | |
| 2. | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге халкы саны (кеше, 2015 елның 1 гыйнварына мәгълүматлар буенча) | |
| 3. | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге башлыгы Ф.И.Ат.ис. | |
| 4. | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге башлыгы белән элемтә өчен мәгълүмат: | |
| 4.1. | почта адресы (индексны күрсәтеп) | |
| 4.2. | телефоны/факсы (торак пунктның федераль кодын күрсәтеп) | |
| 4.3. | электрон почта адресы | |
| 4.4. | интернет-сайты адресы | |
| 5. | җаваплы үтәүченең Ф.И. Ат.ис. | |
| 6. | Җаваплы үтәүче белән элемтә өчен мәгълүмат: | |
| 6.1. | җаваплы үтәүченең телефоны (торак пунктның федераль кодын күрсәтеп) | |
| 6.2. | җаваплы үтәүченең электрон почта адресы | |

Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының 2015 ел, 30 октябрь, 828 нче карары белән расланды

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре арасында «Сәламәтлек территориясе» исеменә республика конкурсын үткәрү буенча оештыру комитеты составы

| | |
|---|---|
| Шәйхразиев Васил Габтелгаяз улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, оештыру комитеты рәисе |
| Шакиров Минсәгыйть Закир улы | Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы рәисе, оештыру комитеты рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Вафин Адел Юныс улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры, оештыру комитеты рәисе урынбасары |

Оештыру комитеты әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Гәрәев Эдуард Илдус улы | Россия Федерациясе Наркотиклар әйләнешен тикшерүдә тоту федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| Динниулов Дамир Равил улы | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министры урынбасары (килешү буенча) |
| Зарипов Айрат Ринат улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |
| Зарипова Эльмира Әмир кызы | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры |
| Леонов Владимир Александрович | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре һәм спорт министры |
| Патяшина Марина Александровна | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсен күзәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Сибагатуллин Айрат Миңнемулла улы | Татарстан Республикасы мәдәният министры |

| | |
|---|---|
| Фазлыева Ләйлә Ринат кызы | Татарстан Республикасы Президенты ярдәмчесе (килешү буенча) |
| Фәттахов Энгель Нәвап улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры. |

F:\KARAR\2015\828.docx